Һөнәр сайлау алдында...

Без зур таләпләр куя торган, үзгәрүчән, тиз яраклашуны сораган җәмгыятьтә яшибез. Замана, җәмгыять дә бала алдына зур бурычлар куя. Мәктәпкә килгәндә бала хәрефләр белән таныш, дөньяны күзалларга әзер булырга, ә инде төп мәктәпне тәмамлаганда, ул дөрес һөнәри юнәлеш алып чыгарга тиеш. Ләкин тормыш тәҗрибәсе булмаган яшүсмергә тормышта дөрес юл сайлавы бик авыр. Кем соң мондый вакытта балага ярдәм итәргә, уңышка илтә торган юл сайларга юнәлеш бирергә тиеш? Бала «җиде юл чатында» калып, дөрес юлдан үзе китәргә мәҗбүр була. Без – укытучыларның бу эштә төп бурычы – балага үзенең мөмкинчелекләрен дөрес бәяләргә, тормышны аң белән планлаштырырга, сайлаган юлына дөрес прогноз бирергә өйрәтү.

Безнең мәктәптә профориентация мәсьәләсе – тәрбия мәсьәләсендә төп проблемаларның берсе. Ни өчен?

**Беренчедән,** без авыл җирендә яшибез. Ә авыл – илне туйдыручы, кешелекне алга алып баручы авыл хуҗалыгы тармагы белән бәйле өлкә. Авыл яшәсен өчен, балаларда авылга мәхәббәт тәрбияләү максаты белән үсемлекчелек, терлекчелек, игенчелек тармаклары белән бәйле булган зоотехник, игенче, сыер савучы, эретеп ябыштыручы, балта остасы, ветеринар, тракторчы, шофер кебек һөнәрләргә мәхәббәт тәрбияләргә омтылабыз. Авыл җирендә яшәгән балаларның әти-әниләре дә терлекчелектә, игенчелектә көн күрә бит. Моның белән бергә әти-әниләрнең хезмәтенә дә дан җырлыйбыз. Әхлак тәрбиясенең төп нигезе шуннан башлана. Чөнки кемдер авыл хуҗалыгын да күтәрергә: икмәк, сөт, ит, бәрәңге дә җитештергә тиеш бит.

Соңгы елларда чыгарылыш укучыларының барысы да (сүз безнен мәктәпне генә тәмамлаган укучылар турында гына бармый) җан-фәрманга югары уку йортларына керергә омтыла. Укып бетергәч, аларның яртысы диярлек үзе сайлаган һөнәр буенча китми: я эш тапмый, я бу һөнәр инде аңа ошамый башлаган булып чыга һәм ул бу юнәлештә эшләргә бөтенләй дә кирәк тапмый. Баксаң, алар бу һөнәрне әти-әнисенең кушуы буенча киткән булып чыга.

Менә шулай килеп туган проблемалар без – укытучылырны, ата-аналарны уйланырга мәҗбүр итә дә инде. Бу мәсьәләдә мәктәпкә әле күп эшләргә, күп тырышырга кирәк; мәктәптә һәрбер балага индивидуаль якын килеп, килеп туган таләпләрне истә тотып, бүтән күзлектән карап эш итәргә кирәк.

Укучыларга туган төбәгендә ихтыяҗы аеруча зур булган һөнәр ияләре турында чын мәгълүматлар җитенкерәми. Шулай ук алар әле үз сәләт-мөмкинлекләрен дә тулы мәгънәдә колачлый алмыйлар. Болар барысы да укучыларның уку йортларын кисәк кенә төптән уйламыйча гына сайлауларына китерә.

Теге яки бу профессияне дөрес сайлау өчен укучыга үзенең индивидуаль-психологик мөмкинчелекләрен исәпкә алырга кирәк. Бу шартны үтәгән очракта

ул кирәкле һөнәрне сайлап, адаптация үтеп, озак вакытлар шушы өлкәдә уңышлы хезмәт куя алачак.

Шуларны исәпкә тотып, мәктәбебездә профориентация тәрбиясе системалы рәвештә укучының яшь үзенчәлекләрен исәпкә тотып алып барыла.

Тәрбия өчен мәктәптә төп җаваплы кеше – сыйныф җитәкчесе. Сыйныф белән эшләү өчен төзелгән планында һөнәри тәрбия бирү буенча чаралар каралган.

**I – IV сыйныфлар.** Кече яшьтәге укучыларда хезмәткә мәхәббәт тәрбияләнә, аның җәмгыятьтә һәм тормышта тоткан урыны аңлатыла. Укучылар көчләреннән килгән хезмәт төрләренә тартыла башлый. Бу процесс хезмәт, уен, дөньяны танып-белү формалары аша алып барыла. Бу этапта «Һөнәрләр дөньясында» дигән тематика белән сыйныф сәгатьләре уздырабыз, әти-әниләрнең эш урыннарына экскурсияләр оештырабыз, технология һәм сәнгать дәресләрендә төрле һөнәр ияләре белән таныштырабыз.

**V – VII сыйныфлар.** Бу этапта укучыларда һөнәрләргә карата шәхси кызыксындыру тәрбияләнә, аларның теләкләре һәм мөмкинчелекләре турында модель төзелә.

Бу этапта аерым һөнәр вәкилләре белән очрашулар оештырабыз, коллектив иҗади эшләр, һөнәрләр турында иҗади проектлар төзелә. Аларның тематикасы төрледән-төрле.

**VIII – IX сыйныфлар.** Укучылар белән сайлаячак һөнәрләре турында индивидуаль сөйләшүләр алып барыла, адекват карарлар кабул ителә.

Бу этапта төрле өлкә һөнәр ияләре белән очрашулар уздырабыз, ә 14 яшьтән узган укучыларыбыз җәйге ял вакытында районыбыздагы Мәшгульлек үзәге аша үз теләкләре белән эшкә урнаша. Бу инде – олы тормышка беренче адымнар, чөнки балалар үзләренең эш нәтиҗәләрен хезмәт хакы аша күрә. Болай эшләү безнең мәктәптә күптән инде практикага кертелгән.

**X – XI сыйныфлар** –үз-үзең өстендә эшләү, һөнәри сыйфатлар тәрбияләү, үз-үзеңә бәя бирергә өйрәнү чоры. Бу этапта бездә төрле уку йортларында белем алучы элеккеге еллар чыгарылыш укучылары белән очрашулар, сайланган уку йортларына «Ачык ишекләр” көннәренә барулар оештырыла.

Һөнәри тәрбия бирү – күп аспектлы система, ул уку-укыту процессын да, балаларның психофизик үзенчәлекләрен өйрәнүне дә, психодиагностика үткәрүне дә, электив курслар оештыруны да, укучыларның психологиясен өйрәнүне дә үз эченә ала.

Шулай итеп, мәктәптә дөрес һөнәри тәрбия бирү – бик мөһим. Чөнки ул мәгариф системасын, илнең икътисади системасы белән, ә укучыларның теләкләрен һәм мөмкинчелекләрен киләчәкләре белән бәйли. Җәмгыятьнең алга таба үсеше һәрбер чыгарылыш сыйныф укучысының тормышта үз урынын табуга, дөрес һөнәр сайлап, алга таба илебезгә файда китерүеннән һәм үзенең дә эшеннән канәгатьлек табуына бәйле. Безнең Песәй урта мәктәбе җәмгыять,

мәктәп куйган шушы бурычларны һөнәри тәрбия аша  һәрбер укучыга олы тормышта үз урынын табып, җәмгыятькә файдалы шәхес булып тәрбияләнергә ярдәм итә һәм уңышлы тормышка ашыра.